**«Раслыйм»**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан
Республикасы
мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе,
Мөфти
_____________________ К.И. Сәмигуллин
«___» ______02_____________ 2016 г.

**Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте**
**Казан (Идел буе) федераль университеты**
**Россия ислам институты**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## мәчетләр каршындагы курсларда куллану өчен уку-укыту һәм тәрбия әсбабы республика конкурсы үткәрү турында

Республика конкурсы (алга таба текстта – Конкурс) Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте, Казан (Идел буе) федераль университеты, Россия ислам институты тарафыннан үткәрелә.

### Конкурсның максаты

Мәчетләр каршындагы башлангыч дини белем, дини тәрбия бирү курсларында тәрбия сыйфатын күтәрү.

### Конкурсның бурычлары

- курсларда тәрбия бирүче мөгаллимнәр, остазлар төзегән иң яхшы уку-укыту, тәрбия әсбабын ачыклау;
- алдынгы тәҗрибәне республиканың башка мәчетләр каршындагы курсларда да файдалану;
- конкурска тәкъдим ителгән уку-укыту, тәрбия әсбабын бастыру һәм аны методик кулланма буларак мөгаллимнәргә тәкъдим итү;
- мөгаллимнәрнең һөнәри осталыгын арттыруга этәргеч бирү.

### Конкурсны үткәрү вакыты һәм этаплары

1 этап - уку-укыту, тәрбия әсбапларын җыю (26 февраль – 24 март 2016 ел)
2 этап - конкурс материалларын жюри тарафыннан бәяләү (24 март – 24 апрель 2016 ел)
3 этап - конкурска җибәрелгән уку-укыту, тәрбия әсбабын (әсбапларын) бастыру (24 апрель – сентябрь)
4 этап – конкурс нәтиҗәләре буенча җиңүчеләрне бүләкләү (октябрь 2016 ел).

### Конкурсның номинацияләре

1. Мәктәп яшендәге балалар, яшьләр өчен уку-укыту, тәрбия әсбабы;
2. Зурлар өчен уку-укыту, тәрбия әсбабы.

## Жюри составы

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте хезмәткәрләре, Казан федераль университеты, Россия ислам институты, “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе һәм Татарстан мәчетләре каршындагы курсларда укытучы мөгаллимнәр арасыннан.

## Конкурста катнашу шартлары

Конкурс мәчетләр каршындагы башлангыч дини белем, тәрбия бирүче мөгаллимнәр, остазлар арасында үткәрелә. Конкурска материаллар татар телендә электрон вариантта кабул ителә. Конкурста катнашучы мөгаллим уку-укыту, тәрбия әсбабы белән бергә үзе турында мәгълүмат, адресын һәм телефон номерын җибәрергә тиеш.

Конкурста катнашу турында заявка һәм конкурс материаллары Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтенең фән һәм мәгариф бүлегенә түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 номерлы йорт

Электрон адрес: karibn@mail.ru

Телефон: 88432381761, 89377774084

Координатор: Карибуллин Айдар Әхбәр улы

Мәчетләр каршындагы курсларда куллану өчен уку-укыту һәм тәрбия әсбабы республика конкурсына

З а я в к а

Катнашучының фамилиясе һәм исеме ____________________________

Номинация ____________________________

Катнашучының эш урыны ____________________________

Адресы ____________________________

Телефоны ____________________________